**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КӘКРЕ КҮЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

№ 3

01 апрель 2015 ел

**Санитар чистарту буенча икеайлык үткәрү турында**
**Кәкре Күл авыл җирлеге территориясе**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 18.03.2015 ел, № 430-р боерыгын, Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының 23.03.2015 ел, № 35 боерыгын үтәп һәм авыл җирлеге Уставына таянып Кәкре Күл авыл җирлеге территориясен санитар чистартуны тизләтү һәм торак пунктлар территорияләрен авыл халкының санитар-эпидемиологик һәм экологик иминлегенә җавап бирүче хәлгә китерү максатларында Кәкре Күл авыл җирлеге башкарма комитеты карар итә:

1. 2015 елның 1 апреленнән 31 маена кадәр Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Кәкре Күл авыл җирлеге территорияләрен санитар чистарту буенча икеайлык игълан итәргә.
2. Ике айлык үткәрү буенча эшләрне координацияләү өчен оператив штаб булдырырга (1 нче кушымта).
3. Кәкре Күл авыл җирлеге территориясендә санитар-экологик хәлне яхшырту буенча чаралар планын расларга (2 нче кушымта).
4. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://aksubayevo.tatarstan.ru
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Кәкре Күл авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе: С.С. Елисеев

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ АКСУБАЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КРИВООЗЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
р 06-3752/13
ИНН 1603004871 ОГРН 1061665002519

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Кәкре Күл авыл җирлеге советының
2015 нче елның 1 нче апрелендәге
3 нче номерлы карарына
1 нче кушымта

**Кәкре Күл авыл җирлеге территориясендә икеайлык үткәрү буенча эшләрне координацияләү өчен оператив штаб**

1. Елисеев Сергей Сергеевич Кәкре Күл авыл җирлеге башлыгы, штаб җитәкчесе.
2. Кондрашов Николай Иванович Кәкре Күл СДК директоры. (килешү буенча).
3. Воронин Василий Витальевич 6 нчы сайлау округы депутаты, Түбән Баланда СДК директоры (килешү буенча).
4. Данилов Алексей Сергеевич, 7 нче сайлау округы депутаты.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Кәкре Күл авыл җирлеге  советының
2015 нче елның 1 нче апрелендәге
3 нче номерлы карарына
2 нче кушымта

**Кәкре Күл  авыл җирлеге территориясендә санитар-экологик хәлне яхшырту буенча чаралар планы**

| № п/п | Чаралар | Срок | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1 | Торак пункт территориясен төзекләндерү буенча халык арасында аңлату эшен оештыру | 25.04.2015кадәр | Авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 2 | Чүплек территориясендәге торак пунктлардан чүп чыгаруны оештырырга | Даими | Авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 3 | Халык белән берлектә торак пункт территориясендәге зиратлар территориясен төзекләндерүне оештырырга | 01.05.2015 кадәр | Авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 4 | Рөхсәтсез чүплекләрне ачыклау һәм бетерүне оештыру | Даими | Авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 5 | Йортлар янында санитар тәртип урнаштыруны таләп итеп авыл гражданнарын ишегалдында урап узу | Атна саен | Авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 6 | Торак йортлар, җәмәгать биналары, мәктәпләр, клублар, медпунктлар, балалар бакчалары, мәктәпләр һәм административ бина янында тәртип урнаштыру | 23.04.2015-30.04.2015 | Үз округлары буенча авыл җирлеге депутатлары, мәктәп директорлары, балалар бакчалары мөдирләре, фельдшерлар |
| 7 | Урамнарның һәм торак булмаган йортларның йөрү өлеше янында тәртип урнаштыру | 16.04.2015-09.05.2015 | Авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 8 | Авыл җирлеге территориясендә баганаларны агарту | 09.05.2015кадәр | Авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 9 | Кюветлардан чүп җыю | 16.04.2015-19.04.2015 | Авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 10 | Бөек Ватан сугышы һәйкәлләрен ремонтлау | 09.05.2015кадәр | Авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 11 | Җиңү паркы территориясен | 09.05.2015кадәр | Авыл җирлеге |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | төзекләндерү | | башкарма комитеты |
| 12 | Агач утырту | 09.05.2015кадәр | Авыл җирлеге башкарма комитеты |